**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.03.2020 ел **Чирмешән авылы** №96

**Җирле, районара, республика дәрәҗәсендәге физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чаралары календарь планына кертелгән физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларын үткәрүгә чыгымнар нормативларын раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 19 мартындагы 160 номерлы «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын раслау турында" карары нигезендә һәм җирле, районара дәрәҗәдәге физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларын үткәрүгә чыгымнар нормаларын тәртипкә салу максатларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга (кушымта итеп биреләләр):

- физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларын үткәргәндә спортчыларны, тренерларны һәм белгечләрне тукландыруга чыгымнар нормалары (1нче кушымта);
- физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларын үткәргәндә спортчыларны, тренерларны һәм башка катнашучыларны яшәү белән тәэмин итү чыгымнары нормалары (2нче кушымта);
- спорт чараларына хезмәт күрсәткән өчен спорт хөкемдарларына түләү чыгымнары нормалары (3 нче кушымта);
- спорт чараларын үткәргәндә истәлекле бүләкләр һәм акчалата бүләкләр алу өчен чыгымнар нормалары (4 нче кушымта).

2. Әлеге Карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге буенча тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Чирмешән

муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән башкарыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р.Ш.Долгополовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе И.Н.Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Башкарма комитетының
2020 елның 18 мартындагы 96 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларын үткәргәндә спортчыларны, тренерларны һәм башка катнашучыларны тукландыруга**
**ЧЫГЫМНАР НОРМАЛАРЫ**

| Спорт чараларының исеме | Бер кешегә бер көнгә чыгымнар нормасы, сум |
|---|---|
| 1. Массакүләм физкультура-спорт ярышлары һәм чаралары | 300 кадәр |
| 2.Татарстан Республикасы чемпионатлары, беренчелекләре, кубоклары һәм алар буенча укыту-тренировка (тренировка) чаралары (спартакиадалар, универсиадалар) | 350 кадәр |
| 3. Бөтенроссия ярышлары һәм алар буенча укыту-тренировка (тренировка) чаралары | 600 кадәр |
| 4. Чирмешән муниципаль районы территориясендә | 200 кадәр |
| 5. Чирмешән муниципаль районыннан читтә | 350 кадәр |

Искәрмә:

1. 90 килограммнан артык авырлыктагы һәм (яки) буйлары 190 сантиметрдан югары булган спортчыларга, әлеге кушымта белән билгеләнгән нормалар аерым очракларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә 50% ка кадәр артырга мөмкин.
2. Спорт чараларын уздыру урыннарында оештырылган туклануны тәэмин итү мөмкинлекләре булмаганда, әлеге кушымтада китерелгән чыгымнар нормалары чикләрендә акча бирү рөхсәт ителә.
3. Спорт чараларын үткәргәндә барлык категориядәге спорт хөкемдарлары да туклану белән тәэмин ителми, аларның хезмәте өчен түләү спорт хөкемдарларына әлеге карар белән расланган спорт чараларына хезмәт күрсәтү өчен түләү чыгымнары нормаларына туры китереп башкарыла.
4. Чаралар үткәрүче оешмалар бюджеттан тыш, спонсорлык чаралары, шулай ук гариза взнослары хисабына барлык категориядәге хөкемдарларга туклану өчен компенсацион түләү башкарырга хокуклы.

Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Башкарма комитетының
2020 елның 18 мартындагы 96 номерлы
карарына 2 нче кушымта

**Физкультура-сәламәтләндерү, спорт һәм тренировка чараларын үткәргәндә спортчыларны, тренерларны һәм башка катнашучыларны яшәү белән тәэмин итү ЧЫГЫМНАРЫ НОРМАЛАРЫ**

| Яшәү өчен торак пунктлар категорияләре исеме | Бер кеше өчен көн бәясе, сум |
|---|---|
| 1. Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочи шәһәрләре | 920 кадәр |
| 2. Россия Федерациясе Субъектларының административ үзәкләре:<br>Ерак Төньяк территориясенә кертелгән шәһәрләр, торак пунктлар | 750 кадәр |
| 3. Россия Федерациясе территориясендәге башка шәһәрләр һәм торак пунктлар | 550 - 700 |

Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Башкарма комитетының
2020 елның 18 мартындагы 96 номерлы
карарына 3 нче кушымта

## Спорт чараларына
## хезмәт күрсәтү өчен спорт хөкемдарларына түләү
## ЧЫГЫМНАРЫ НОРМАЛАРЫ

| Хөкемдарлар вазыйфаларының атамасы | Хөкемдарлар категорияләрен исәпкә алып, түләүләр күләме, сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | ХК, БК | 1К | 2К | 3К/Я/С | Категориясез |
| Баш хөкемдар | 650 | 550 | - | - | - |
| Баш хөкемдар - секретарь | 650 | 550 | - | - | - |
| Баш хөкемдарның, баш секретарьның урынбасары | 600 | 500 | 400 | - | - |
| Хөкемдарлар | 560 | 450 | 380 | 350 | 300 |
| **Спортның команда уен төрләре** | | | | | |
| Уенның баш хөкемдары | 380 | 350 | - | - | - |
| Уенның баш хөкемдары ярдәмчесе | 320 | 300 | - | - | - |
| Инспектор (техник делегаты, комиссар) | 380 | - | - | - | - |
| Хөкемдарлар (бригада составында) | 290 | 270 | 250 | 230 | 200 |

Шартлы билгеләмәләр:
ХК – халыкара категорияле спорт хөкемдары;
БК- бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары;
1К – беренче категорияле спорт хөкемдары;
2К- икенче категорияле спорт хөкемдары;
3К –өченче категорияле спорт хөкемдары;
Я/С – яшь спорт хөкемдары.

Искәрмә:

1. Түләү күләме ярышларның бер көненә хезмәт күрсәтү өчен каралган, спортның команда уен төрләреннән тыш, анда түләүләр бер уенга хезмәт күрсәтү өчен башкарыла (футбол, алкалы хоккей, баскетбол, волейбол, су полосы, гандбол, туплы хоккей, чирәмдәге хоккей, бейсбол, регби һ. б.).
2. Ярышларның әзерлек һәм йомгаклау этапларында баш хөкемдарга, баш хөкемдарга-секретарьгә, баш хөкемдар урынбасарына һәм баш хөкемдар-секретаре урынбасарына яшәү, эш өчен түләү өстәмә рәвештә 2 көнгә арта.
3. Хөкемдарлар коллегияләренең (бригадаларының) составы саны спорт төрләре буенча ярышлар уздыру турындагы расланган кагыйдәләр нигезендә билгеләнә.
4. Халыкара, бөтенроссия ярышлары, Татарстан Республикасы чемпионатлары һәм кубоклары уеннарын оештыру һәм үткәрү буенча контрольне гамәлгә ашыру өчен инспекторлар яки техник делегатлар билгеләнергә мөмкин, уеннарның баш хөкемдарлары өчен күләмдәге түләү белән

Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Башкарма комитетының
2020 елның 18 мартындагы 96 номерлы
карарына 4 нче кушымта

# Спорт чараларын үткәргәндә истәлекле бүләкләр һәм акчалата бүләкләр алу өчен ЧЫГЫМНАР НОРМАЛАРЫ

| №<br>№<br>п/п | Спорт чараларының исеме | Истәлекле бүләкләр һәм акчалата бүләкләрнең бәясе (сумнарда) | |
|---|---|---|---|
| | | команда ярышлары | шәхси ярышлар |
| 1. | Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелә торган халыкара ярышлар<br>I урын<br>II урын<br>III урын | <br><br><br>2 000 кадәр<br>1 800 кадәр<br>1 600 кадәр | <br><br><br>1 500 кадәр<br>1 300 кадәр<br>1 100 кадәр |
| 2. | Россия чемпионатлары, беренчелекләре һәм Кубоклары, шулай ук массакүләм физкультура-спорт чаралары финаллары:<br>I урын<br>II урын<br>III урын | <br><br><br><br>1 500 кадәр<br>1 300 кадәр<br>1 100 кадәр | <br><br><br><br>1 200 кадәр<br>1 000 кадәр<br>800 кадәр |

Искәрмә:

1. Истәлекле бүләкләрнең бәясенә эквивалент акчаны бүләкләү сыйфатында бирү тыела.

2. Спортның уен команда төрләрендә һәм команда дисциплиналарында призлы урыннар алган командалар кубоклар, ә командаларда катнашучылар - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге медальләре һәм дипломнары (грамоталары) белән бүләкләнә.

3. Чирмешән муниципаль районы кубокларында чыгыш ясау нәтиҗәләре буенча I урынны яулаган катнашучыларга кубок, медаль һәм диплом, ә II һәм III урыннар өчен призерларга медальләр һәм дипломнар тапшырыла.

4. Җиңүче спортчыларның һәм призерларның (командаларнын) тренерлары Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге дипломнары (грамоталары) белән бүләкләнәләр.